ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.01.2024 Олы Кайбыч ав. № 9

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Федоровский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.
2. Гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы булып Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты тора.
3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты: 2024 елның 16 феврале, 10 сәг 00 мин.
- үткәрү урыны: Кайбыч районы, Федоровский ав., Тутаев ур., 41 й. адресы буенча урнашкан Федоровский авыл җирлегенең административ бинасы;
- 2024 елның 16 февраленә кадәр тикшерелә торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелергә мөмкин булган адреслар:

Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге;

Кайбыч районы, Федоровский ав., Тутаев ур., 41 й. - Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитеты.

4. Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Башкарма

комитетына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Ю.В. Гайнуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесенең
беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллина